Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

03 февраль 2020 ел № 121

2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 маенда
Әлмәт шәһәрендә Бөек Ватан сугышында
җиңүнең 75 еллыгына багышланган
репетицияләр һәм тантаналы чаралар
оештыру һәм үткәрү турында

2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 май көннәрендә Әлмәт шәһәрендә Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына багышланган репетицияләр һәм тантаналы чаралар үткәрү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 маенда репетиция һәм тантаналы чаралар уздырганда Әлмәт шәһәре урамнарын ябу схемалары буенча Әлмәт шәһәрендә 2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 маенда маршрутлар буенча Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына багышланган репетицияләр һәм тантаналы чаралар үткәрергә (1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталар)

2. 2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 маенда репетиция һәм тантаналы чаралар уздырганда Әлмәт шәһәре урамнарын ябу схемалары буенча 2020 елның 05, 07, 08 һәм 09 майда 06:00 сәгатьтән 23:00 сәгатькә кадәр Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенә (Гиздатуллин В.М.) Әлмәт шәһәрендә урамнарны ябуны тәкъдим итәргә .

3.«Автомобиль юллары шәһәр идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә (Хаҗипов Р.М.) әлеге карарга 1, № 2, № 3, № 4 кушымталары нигезендә урыннарда вакытлыча юл билгеләре урнаштырырга тәкъдим итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) халыкка Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына багышланган тантаналы чаралар уздыру турында мәгълүмат бирергә.

5. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Район Башкарма комитетының Төзелеш, элемтә, транспорт һәм юл хуҗалыгы идарәсенең транспорт һәм юл хуҗалыгы бүлегенә (Җамалетдинов А.А.) җәмәгать транспорты маршрутлары хәрәкәте схемасына үзгәрешләр кертергә.


7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«03» гыйнвар № 121 карарына
1 нче кушымта

2020 елның 05,07,08 маенда Әлмәт шәһәре урамнарын репетицияләр вакытында ябу схемасы




2020 елның 05, 07, 08 маенда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү репетицияләрен үткәрү вакытына чыгу юлларын ябу

12:00 – 18:00 – Җиңү парады репетицияләре.
Заслонов урамыннан алып Радищев урамына кадәр Ленин урамындагы хәрәкәтне чикләү.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«03» гыйнвар № 121 карарына
2 нче кушымта

2020 елның 09 маенда тантаналы чаралар уздырганда Әлмәт шәһәре урамнарын ябу схемасы




2020 елның 09 маенда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү чарасын үткәрү вакытына чыгу юлларын ябу

06:00 - 23:00 – «Мәңгелек ут» һәйкәл-монументына веноклар салу.
Радищев урамыннан М.Җәлил урамына кадәр Тимирязев урамында хәрәкәтне чикләү.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«03» гыйнвар № 121 карарына
3 нче кушымта

2020 елның 09 маенда тантаналы чаралар уздырганда Әлмәт шәһәре урамнарын ябу схемасы




2020 елның 09 маенда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү чарасын үткәрү вакытына чыгу юлларын ябу

8:00 – 18:00 – Җиңү Парады, массакүләм күңел ачулар.
Төзүчеләр урамыннан Радищев урамына кадәр Ленин урамында хәрәкәтне чикләү
Радищев урамыннан М.Җәлил урамына кадәр Белоглазов урамында хәрәкәтне чикләү

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«03» гыйнвар № 121 карарына
4 нче кушымта

2020 елның 09 маенда тантаналы чаралар уздырганда Әлмәт шәһәре урамнарын ябу схемасы



2020 елның 09 маенда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү чарасын үткәрү вакытына чыгу юлларын ябу

17:00 - 23:00 - концерт программасы.
Радищев урамыннан М.Җәлил урамына кадәр Ленин урамында хәрәкәтне чикләү
Ленин урамыннан Белоглазов урамына кадәр Гагарин урамында хәрәкәтне чикләү

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева